## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“29” март 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 29 мартында 13 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пунктында гражданнар Җыенының 16.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Кызыл-Утар авылы территориясен чистарту (агачлар кисү, үлән чабу), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү).”

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 66 (алтмыш алты) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 37 (утыз җиде) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 37 (утыз җиде) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кызыл Утар торак пунктында гражданнар Җыенының 16.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү” :

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Кызыл-Утар авылы территориясен чистарту (агачлар кисү, үлән чабу), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм

электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү).”

мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кызыл Утар авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Кашшапов А.Х.